ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2026 ел Баулы шәһәре № 91

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 октябрендәге 213 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 3 маендагы 114 номерлы, 2024 елның 12 февралендәге 14 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Баулы муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәтен күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында 2026 елның 31 июлендәге 9973/26 номерлы хатларына нигезләнеп, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 октябрендәге 213 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (алга таба – Регламент) (2023 елның 3 маендагы 114 номерлы, 2024 елның 12 февралендәге 14 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентның 1.3 пунктындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Оешмага беренче чиратта кабул ителү хокукына ия балалар:

инвалид балалар һәм ата-аналарының берсе инвалид булган балалар;

күп балалы гаиләләрдән булган балалар;

полиция хезмәткәрләренең балалары, шул исәптән хезмәт вазифаларын башкарганда алынган җәрәхәт яки сәламәтлеккә башка зыян китерү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) полиция хезмәткәрләренең балалары; полициядә хезмәт иткән вакытта алынган авыру нәтиҗәсендә вафат булган полиция хезмәткәренеке; хезмәт вазифаларын башкарганда алынган җәрәхәт яки сәламәтлеккә башка зыян китерү нәтиҗәсендә һәм алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеге булмаган өчен хезмәттән азат ителгән Россия Федерациясе гражданнарының балалары; хезмәт вазифаларын башкарганда алынган җәрәхәт яки сәламәтлеккә башка зыян китерү нәтиҗәсендә яки полициядә хезмәт иткән вакытта алынган һәм алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеге булмаган авыру нәтиҗәсендә хезмәттән азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булган Россия Федерациясе гражданнарының балалары; полиция хезмәткәре – Россия Федерациясе гражданины тәрбиясендә торучы (булган) балалар;

хәрби хезмәткәрләрнең балалары;

махсус исемнәр алган һәм җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәтендә, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче, шул исәптән хезмәт вазифаларын башкарганда алынган җәрәхәт яки сәламәтлеккә башка зыян китерү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләрнең; хезмәт иткән вакытта алынган авыру нәтиҗәсендә вафат булган хезмәткәрләрнең; хезмәт вазифаларын башкарганда алынган җәрәхәт яки сәламәтлеккә башка зыян китерү нәтиҗәсендә һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеге булмаган өчен хезмәттән азат ителгән хезмәткәрләрнең; хезмәт вазифаларын башкарганда алынган җәрәхәт яки сәламәтлеккә башка зыян китерү нәтиҗәсендә яки хезмәт иткән вакытта алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеге булмаган авыру нәтиҗәсендә хезмәттән азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булган хезмәткәрләрнең; хезмәткәр – Россия Федерациясе гражданины тәрбиясендә торучы (булган) балалар;

укытучылар балалары.».

Регламентның 1 нче, 9 нчы кушымталарын яңа редакциядә бирергә (кушымтада).

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесен Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын эшкәртүче белем бирү оешмаларына гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә алу һәм укырга кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүне вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләре әлеге карарны ата-аналар (законлы вәкилләр) белән таныша алырлык урыннарда урнаштырырга тиеш.

Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://www.pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында: http://www.bavly.tatarstan.ru адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д. Л. Бакиров

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль
районында Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2026 елның 5 августындагы
91 карары редакциясендә
«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту
программаларын гамәлгә ашыручы
муниципаль мәгариф оешмаларына
балаларны исәпкә кую һәм җибәрү»
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
Административ регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары турында белешмәләр

| Оешманың атамасы | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Оешма адресы/сайты | Телефон номеры | Оешманың эш режимы, җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «1 нче «Алсу» балалар бакчасы» муниципипаль бюджет | Хаҗиәхмәтова Айгөл Альберт кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре, Һ.Такташ ур., 11 й. ds1bav@mail.ru | (85569) 5-21-29 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: сишәмбе, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | | | | пәнҗешәмбе 14:00 - 15:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «2 нче «Рябинушка» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Галиуллина Ильмира Ринат кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре, Һ.Такташ ур., 5 й. ryabinka1951@ mail.ru | (85569) 5-46-27 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: көн саен 08:00 - 17:00 (12:00 -13:00 төшке аш) |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «4 нче «Ромашка» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Расторгуева Наталия Николаевна | 423930, ТР, Баулы шәһәре, Гоголь ур., 17 ds4.bav@mail.ru | (85569) 5-62-56 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: дүшәмбе 08:00 - 09:00, сишәмбе, пәнҗ ешәмбе 16:00 - 17:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «5 нче «Бәләкәч» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Зиннатуллин а Эльвира Фердинанд кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре,Татарста н ур., 4 doy5beleket@ mail.ru | (85569) 5-96-75 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: сишәмбе 14:00 - 17:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “7 нче "Колокольчик" балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Китапова Зилә Галимҗан кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре, Ваһапов ур., 37 rkolokolchik@bk.ru | (85569) 6-06-01 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: сишәмбе, пәнҗ ешәмбе 14:00 - 17:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «8 нче «Виктория» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Садыйкова Гөлнара Зәкәри кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре, Горюнов ур, 3а mdoj8@yandex. ru | (85569) 5-23-99 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: сишәмбе, пәнҗ ешәмбе 14:00 - 16:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «9 нчы «Алёнка» балалар бакчасы» муниципаль бюджет | Зверева Регина Сагир кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре, Пионерская ур, 8 Ds9.bav@yandex.r u | (85569) 5-35-10 | Эш режимы: 06:00 - 18:00; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: көн саен 08:00 - 17:00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | | | | (12:00 - 13:00 төшке аш) |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «12 нче «Алтынчәч» балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Овчинникова Гүзәл Әхәт кызы | 423930, ТР, Баулы шәһәре, С.Сәйдәшев ур., 20 altinchech_12@ mail.ru | (85569) 5-40-47 | Эш режимы: 07:00-17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: сишәмбе, пәнҗешәмбе 14:00-16:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бирү учреждениесе «Александровка балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Фәтхинурова Эльвира Рафаэль кызы | 453926, ТР, Баулы районы, Александровка авылы Чапаев ур., 9 ds.aleksandrovka @mail.ru | (85569) 3-73-49 | Эш режимы: 06:30 - 17:00; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: чәршәмбе 08:00 - 12:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Исәргәп балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Чулпанова Гөлназ Камил кызы | 423941, ТР, Баулы районы, Исергәп авылы, Совет ур., 166 isergapsadik@ mail.ru | (85569) 3-21-57 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; кабул итү сәгатьләре җитәкче: көн саен 08:00 - 11:00 13:00 - 16:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Кызылъяр балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Фәтхетдинова Тамара Хашим кызы | 423940, ТР, Баулы районы, Кызылъяр авылы, Гагарин ур., 26 Киров ур., 44Б (яңа бина) kzyl-yar.sadik@mail.ru | (85569) 3-31-17 | Эш режимы: 06:30 - 17:00; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: көн саен 08:00 - 11:00 13:00 - 16:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Покров-Урыстамак балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Жирнова Светлана Васильевна | 423942, ТР, Баулы районы, Покров Урыстамак авылы, Советская ур., 61В rodnihok@inbox.ru | (85569) 3-25-66 | Эш режимы: 07:00 - 17:30; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: чәршәмбе 14:00 - 17:00 |
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Потап-Томбарлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Давыдова Галина Михайловна | 423935, ТР, Баулы районы, Потап-Томбарлы авылы, Советская ур., 35а potap_dou@mail.ru | (85569) 3-11-58 | Эш режимы: 06:30-17:00; җитәкченең кабул итү сәгатьләре: көн саен 08:00 - 17:00 (12:00 - 13:00 төшке аш) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Татар Томбарлысы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Шәгалиева Әлфия Сәйрин кызы | 423921, ТР, Баулы районы, Татар Томбарлысы авылы, Ленин ур., 74 tumbarlasadik@mail.ru | (85569) 3-82-24 | Эш режимы: 07:30 - 17:30; җитәкченең каб ул итү сәгатьләре: көн саен 08:00 - 17:00 (12:00 - 13:00 төшке аш) |

---

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль
районында Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2026 елның 5 августындагы
91 карары редакциясендә
«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту
программаларын гамәлгә ашыручы
муниципаль мәгариф оешмаларына
балаларны исәпкә кую һәм җибәрү»
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
Административ регламентына
2 нче кушымта

Баланы исәпкә кую һәм мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына җибәрү турында
гариза

Гариза бирүченең Ф.И.А. (атасының исеме - булган очракта)_______________________________________________

Статусы
_______________________________________________________________________________
(баланың анасы, атасы, законлы вәкиле – кирәклесен күрсәтергә)

Туу датасы
______________________________________________________________________
(көне, ае, елы)

Шәхесне таныклый торган документ______________________________________________

серия, номеры___________________ кем тарафыннан һәм кайчан
бирелгән___________________________________

_____________________________________________________бүлекчә коды____________
Гражданлыгы ____________________________________________________
(Россия Федерациясе гражданины (гражданкасы),
_____________________________________________________________________________
чит ил гражданины, гражданлыгы булмаган зат, шул исәптән чит илдә яшәүче ватандаш (кирәклесен күрсәтергә)
Опека урнаштыру турындагы документның реквизитлары (булган очракта)________________________
Электрон почта адресы (булган очракта) __________________________________________

Контактлы телефоннар________________________________________________________________

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында урын бирү өчен исәпкә куюны үтенәм
№________________________________________________________
Баланың Ф.И.А. (атасының исеме - булган очракта)______________________________________________
_____________________________________________________________________________
Туу датасы ________________________________________________________________________
Баланың җенесе________________________________________________________________________
Баланың туу турында таныклыгы __________________________________________________
(сериясе, номеры, бирү датасы)
Туу турында акт язуының номеры һәм датасы_______________________________________________
Адрес:
яшәү урыны буенча теркәлү ______________________________________________
фактик яшәү урыны (булу урыны) ___________________________

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасына язылуның теләп куелган датасы________________________
Булу режимы ____________________________________________________________________
(12 сәгать, 10,5 сәгать)
Теләгән укыту теле____________________________________________________________
(белем алу теле, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган тел, шул исәптән рус теле туган тел буларак)

Баланың тулы туган яки тулы булмаган туган абыйлары һәм (яки) апа-сеңелләре, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында укый торган булуы

_____________________________________________________________________________

(ата-ана (законлы вәкил) тарафыннан баланы кабул итү өчен сайланган белем бирү оешмасында укый торган тулы туган яки тулы булмаган туган абыйларның һәм (яки) апа-

сеңелләрнең фамилияләре (-иясе), исеме (исемнәре), атасының исеме (соңгысы - булган очракта) күрсәтелә)

Махсус билгеләр:
Баланы адаптив белем бирү программасы буенча укытуга ихтыяҗ, шәхси тернәкләнү программасына туры китереп, инвалид балаларны һәм сәламәтлегә ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту һәм тәрбияләүне оештыру өчен махсус шартлар тудыру (булган очракта)

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

ихтыяҗны раслаучы документның атамасы, номеры, бирү датасы, гамәл вакыты (ПМПК карары, инвалидлыкны теркәү турындагы справка, сәламәтлек саклау органы справкасы)

Төркем юнәлешлелеге________________________________________________

(гомуми үсеш, ПМПК карары булган очракта компенсацияләүче - сәламәтләндерүче, сәламәтлек саклау органы справкасы булган очракта)

Компенсацияләүче: хәрәкәт аппараты бозылуы булган балалар өчен; фонетик-фонематик тел бозылулары булган балалар өчен; саңгырау балалар өчен; начар ишетүче балалар өчен; сукыр балалар өчен; начар күрүче балалар өчен; хәрәкәт аппараты бозылулары булган балалар өчен; психик үсеше тоткарланган балалар өчен; интеллект бозылуы булган балалар өчен; аутистик спектр һәм авыр күпсанлы үсеш бозылулары булган балалар өчен.
Сәламәтләндерүче: ашамлыкка аллергиясы, целиакия, фенилкетонурия булган балалар өчен, еш авырый торган балалар өчен, туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен, шикәр диабеты булган балалар өчен.

Минем тарафтан күрсәтелгән өстенлекле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә урыннар булмаган очракта, башка вариантлар тәкъдим итәргә

_____________________________________________________________________________

(әйе, юк)

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасына урнашу өчен махсус ярдәм чараларына хокук (булган очракта)

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

(ташлама төре, документ номеры, бирү датасы, гамәлдә булу вакыты)

Гаризага түбәндәге документларны терким:
1. _____________________________________________________________________________

2. ________________________________________________________________________________________________
–

3. ________________________________________________________________________________________________
–

4. ________________________________________________________________________________________________
–

Тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплылык турында кисәтелдем

______________________ ______________________________
(дата) (гариза бирүче имзасы)